Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Зур Мәшләк авыл
җирлеге Советы

**8 номерлы КАРАР**

Зур Мәшләк авылы 2019 елның 13 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында 15.04.2019 ел, №63-ФЗ «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2015 елның 15 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 30 октябрендәге 15 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 17 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3.2 пунктының 12 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2) 3.2 пунктның 11 абзацында «1 ноябрьгә кадәр» сүзләрен «31 декабрьдән дә соңга калмыйча»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы,М.Горький урамы,50А йорт; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллин